БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 03 2023 ел № 129

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына (2017 елның 6 сентябрендәге 225 номерлы, 2019 елның 28 декабрендәге 392 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 384 номерлы, 2022 елның 29 гыйнварындагы 68 номерлы, 2022 елның 8 ноябрендәге 324 номерлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Укучыларны баланслы кайнар ризык белән тәэмин итү, аларның сәламәтлеген саклау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декарендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-20 СанПиН таләпләрен үтәү максатларында, «2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Үзгәреш кертергә һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарының 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 8 сум 80 тиен субсидиядән һәм ата-ана түләвеннән торган кайнар аш белән тәэмин итәргә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов